# Исәнмесез!
# Хәерле көн!
# Көнегез файдалы узсын!

# Сез нинди сүз төркемнәрен беләсез?

# Алмашлык турында нәрсәләр беләсез?

***Ул*** алмашлыгын килешләрдә төрләндереп күрсәтегез

***Кем?, нәрсә?, кайда?, кая?, кайчан?, ничә?, ничәнче? нинди? кайсы?, кайдан?, нигә?, ник?*** кебек сүзләр кайсы сүз төркеменә керәләр икән, ничек уйлыйсыз? Алар сөйләмдә ни өчен кирәк?

Болар- **<u>сорау алмашлыклары (вопросительные местоимения).</u>** Алар мөстәкыйль сүз төркемнәрен алыштырып киләләр, аларның сорауларына җавап бирәләр.(Они заменяют самостоятельные части речи и отвечают на их вопросы)

**Күчереп языгыз. Җөмләләрдән сорау алмашлыкларын табыгыз. Алар кайсы сүз төркемнәрен алыштырганнар?**

1) -Дәрестә кемнәр юк?-дип сорады укытучы.
2) –Нинди төстәге күлмәгемне киим? – диде Гафифә.
3) –Ничегрәк ял иттегез?
4) -Улыгыз ничәнчене тәмамлады?
5) –Сез бүген дәрестә нишләдегез?

Б.к. *кем? нәрсә?*
И.к. *кемнең? нәрсәнең?*
Ю.к. *кемгә? нәрсәгә?*
Т.к. *кемне? нәрсәне?*
Ч.к. *кемнән? нәрсәдән?*
У.В.к. *кемдә? нәрсәдә?*

-Улыгыз ничәнчедә (сыйныф) укый?
-Кайсыгыз (кем) белә?

Б.к. *ничәнче? кайсы?*
И.к. *ничәнченең? кайсының?*
Ю.к. *ничәнчегә? кайсына?*
Т.к. *ничәнчене? кайсын?*
Ч.к. *ничәнчедән? кайсыннан?*
У.В.к. *ничәнчедә? кайсында?*

# Нинди нәтиҗә ясый аласыз?

# Сорау алмашлыкларының кайберләре килешләрдә төрләнә (Некоторые вопроситетельные местоимения склоняются по падежам)

# 49 нчы күнегүне эшләгез.

Белемнәрегезне тикшерегез:

- ***сорау алмашлыклары дип нинди сүзләрне атыйлар?***
- ***аларны без сөйләмдә ни өчен кулланабыз?***
- ***кайсы сорау алмашлыклары килешләрдә төрләнә?***